РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

№ 26 13.11.2024

РЕШЕНИЕ КАРАР

Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 28.04.2018 №9 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында”

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.09.2024 елгы №829 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 28.04.2018 елгы №9 карарына (Советның 09.11.2020 №12, 15.10.2022 №17, 19.12.2022 №24, 08.08.2024 №15 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга.»;

**1.2.** Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 январеннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен

расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Килдебәк авыл җирлеге
Советының 13.11.2024 №26 карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге Башлыгы | 19 173 |
| Депутатлар | 13 990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13 990 |